**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы советы КАРАРЫ**

**2019 елның 20 ноября 2019** **№ 226**

**Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслаштыру максатларында субсидияләр бирү турында**

Россия Федерациясе Бюджет кодексының 142.3 статьясы нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советы КАРАР чыгарды:

1. Җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслаштыру максатларында Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр бирү тәртибен расларга.

2. Карар 2020 елның 1 гыйнварыннан барлыкка килгән хокук мөнәсәбәтләре буенча үз көченә керә.

3. Әлеге карарның үтәлешен тикшереп торуны Кама Тамагы муниципаль районы Советының бюджет, салымнар һәм финанслар буенча даими комиссиясенә йөкләргә.

**Кама Тамагы муниципаль районы башлыгы,**
**муниципаль район Советы рәисе** **Н. А. Вазыйхов**

Кама Тамагы муниципаль
район Советының
2019елның 22 ноября 226 номерлы
карарына 1 нче кушымта

**Татарстан Республикасы**
**Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы-**
**Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр**
**һәм авыл җирлекләре бюджетларына җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итүбуенча җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен башкарганда барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслаштыру максатларында**
**субсидияләр бирү тәртибе**

1. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләр җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне (алга таба-субсидияләр) хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында бирелә.

2. Субсидияләр Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Агымдагы финанс елына һәм план чорына Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты турында»гы карарында каралган бюджет ассигнованиеләре һәм бюджет йөкләмәләренең лимитлары чикләрендә бирелә. Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Агымдагы финанс елына һәм план чорына Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты турында»гы карарына һәм (яисә) Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетының тиешле финанс елында субсидияләр бирүгә бюджет ассигнованиеләре күләмнәрен төгәлләштерүне күздә тоткан үзгәрешләр кертелгән очракта, килешүгә тиешле үзгәрешләр кертелә.

3. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Башкарма комитеты әлеге карар нигезендә бирелә торган бюджет ассигнованиеләрен төп бүлүче булып тора.

4. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре бюджетларына субсидияләрне бүлү Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Кама Тамагы муниципаль районының тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында»гы карары белән раслана.

5. Субсидияләр бирүнең максатлары һәм тәртибе Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр, авыл җирлеге башкарма комитеты арасында төзелә торган килешүләр белән билгеләнә.

6. Килешүдә түбәндәге төп нигезләмәләр булырга тиеш:

а) субсидияләрнең максатчан билгеләнеше;

б) субсидия бирү һәм аны тоту шартлары;

в) субсидия бирүгә каралган бюджет ассигнованиеләре күләме;

г) субсидия күчерү графигы;

д) субсидия бирү һәм тоту өчен билгеләнгән шартларның үтәлешен тикшереп тору тәртибе;

е) финанс тәэминаты чыганагы субсидия булган чыгымнарны тормышка ашыру турында хисап бирү сроклары һәм тәртибе.

7. Килешү проектын әзерләү Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан башкарыла.

8. Килешү проекты Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитетына һәм Татарстан Республикасының Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр, авыл җирлеге башкарма комитетына җибәрелә.

9. Килешү Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты җитәкчесе һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр һәм авыл җирлеге башкарма комитеты җитәкчесе тарафыннан имзалана.

10. Субсидия алу өчен Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр, авыл җирлеге башкарма комитеты Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан билгеләнгән срокларда түбәндәге документларны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Финанс-бюджет палатасы тапшыра:

Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты тарафыннан расланган форма буенча субсидияләр бирүгә гариза.

11. Кабул ителгән Татарстан Республикасы бюджетына бирелә торган субсидия күләме түбәндәге формула ярдәмендә билгеләнә:

$$\mathbf{С}_{\text{мт}} = \mathbf{П}_{i} \times \mathbf{У}_{i} \times \mathbf{К}_{i}$$

$С_{мт}$ – Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Советының «Кама Тамагы муниципаль районының тиешле финанс елына һәм план чорына бюджеты турында» гы карары белән, Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетының керем мөмкинлекләреннән һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы шәһәр, авыл җирлекләренең чыгым ихтыяҗларыннан чыгып, субсидияләр бирү өчен бюджет ассигнованиеләренең гомуми күләме;

$П_i$ – i-җирлегенең җирле әһәмияттәге мәсьәләләрне хәл итү буенча Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының шәһәр һәм авыл җирлекләре җирле үзидарә органнары вәкаләтләрен үтәгәндә барлыкка килә торган чыгым йөкләмәләрен финанслашу максатларында финанс ярдәме күрсәтү ихтыяҗы күләме;

$У_i$ – Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджетыннан чыгым йөкләмәләрен финанслашуның иң чик дәрәҗәсе;

$K_i$ – Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының берләштерелгән бюджетының суммар ихтыяҗлары һәм керем мөмкинлекләре бәяләрендәге аерма нисбәтенең әһәмиятенә бәйле рәвештә билгеләнә.

12. Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы тарафыннан шәһәр, авыл җирлекләре бюджетларына федераль казначылыкның Татарстан Республикасы буенча идарәсенең территориаль органнары счетына субсидияләр күчерелә.

13. Субсидияләр бирү шартларын бозган очракта тиешле акчалар Россия Федерациясе бюджет законнарында билгеләнгән тәртиптә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты керемenә күчерелергә тиеш.

14. Субсидияләр бирү елыннан соң килүче елның 1 гыйнварына файдаланылмаган субсидияләр калдыгы Россия Федерациясе Бюджет кодексында билгеләнгән таләпләр нигезендә Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы бюджеты керемenә кире кайтарылырга тиеш.

15. Башка бюджетара трансфертларның максатчан кулланылышын тикшереп торуны Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районы Башкарма комитеты һәм Татарстан Республикасы Кама Тамагы муниципаль районының Финанс-бюджет палатасы законнары нигезендә гамәлгә ашыралар.